Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

КАРАР № 5-1

Бәтке авылы 2024 елның 01 нче августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге
Советының 17.08.2023 №14-1 карары белән
расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге
территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль
контроль турында нигезләмәнең үз көчен
югалтуын тану хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге Советы Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге Советының 17.08.2023 №14-1 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы: Ф.М.Динмөхәммәтов